РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«26» март 2020 ел г. Альметьевск № 434

Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Балигъ булмаганнарның күчемсез милеген читләштерү буенча алыш-биреш ясауга алдан рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында»гы 2020 елның 23 гыйнварындагы 59 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Федераль законын, «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына опека һәм попечительлек өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2008 елның 20 мартындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының «Опека һәм попечительлек өлкәсендә Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча вәкаләтле орган турында» 2008 елның 04 апрелендәге 232 номерлы карарын үтәү йөзеннән

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. «Балигъ булмаганнарның күчемсез милеген читләштерү буенча алыш-биреш ясауга алдан рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Әлмәт муниципаль районы башкарма комитетының 2020 елның 23 гыйнварындагы 59 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

карарга 1 нче кушымтада 2.5 пунктының 2 бүлегендә 5 пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:

«5) читләштерелә торган һәм яңа сатып алына торган күчемсез милеккә техник паспортларның күчермәләре. Шәхси торак йорт сатып алганда күчемсез милек объектының техник характеристикалары турында мәгълүмати белешмә бирергә;».

2. Район Башкарма комитетының хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга,

Зак. № 305-2000

Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары А.Н. Подоваловка йөкләргә.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе М.Н. Гирфанов

ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ